ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК

ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.03.2026 г.Лениногорск № 6

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 5 апрелендә 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге автомобиль юлларында парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм алардан, шул исәптән түләүле нигездә, файдалану тәртибе турындагы (17.02.2023 ел, №9 редакциядә)нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы региональ яисә муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкаларны (парковка урыннарын) булдыру һәм алардан, шул исәптән түләүле нигездә, файдалану тәртибен раслау турында» 2014 елның 29 ноябрендәге 928 номерлы карарына (03.06.2024 ел редакциясе) таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы белән, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.«Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында парковкаларны (парковка урыннарын) булдыру һәм алардан, шул исәптән түләүле нигездә, файдалану тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017елның 5 апрелендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм алардан, шул исәптән түләүле нигездә, файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. пунктының «б» пунктчасының 2 абзацы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күрсәтелгән транспорт чараларында «Инвалид» таныклык билгесе урнаштырылырга тиеш, һәм бу транспорт чаралары турында мәгълүмат «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына кертелергә тиеш».

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.А. Мөхәмәтшин

Хәйбрахманов И.Р.
5-44-72